ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30 ноябрь, 2019 ел. Казан шәһәре № 403

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 августындагы 204 номерлы боерыгы белән расланган Электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына үзгәреш кертү хакында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карарын көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 834 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын чыгарылуга бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 20 августындагы 204 номерлы боерыгы белән расланган Электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм

җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына, аны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. 3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.П. Борисовага йөкләргә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «20» август, 2019 ел, № 204 боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «30» ноябрь, 2019 ел, № 403 боерыгы редакциясендә) белән расланды

**Электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент, электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте (алга таба - дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: электр һәм җылылык энергиясен җитештерүне гамәлгә ашыручы, үзләренә карата бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу гамәлгә ашырыла торган оешмалар (оештыру-хокук формасына һәм милекчелек формасына бәйсез рәвештә) яки шәхси эшкуарлар, электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр энергиясен һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларында электр һәм җылылык энергиясе җитештерүне гамәлгә ашыручы оешмалардан һәм шәхси эшкуарлардан тыш.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Дәүләт комитеты урнашкан урын: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й.

Дәүләт комитетының эш графигы:

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе-пәнҗешәмбе | 8.00 - 17.00 (тәнәфес: 12.00 сәг. 12.45 сәг. кадәр) |
| Җомга | 8.00 - 15.45 (тәнәфес: 12.00 сәг. 12.45 сәг. |

| | |
|---|---|
| | кадәр) |
| Шимбә, якшәмбе | ял |

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Дәүләт комитетының эш көннәрендә.

Җәмәгать транспортында «Толстой» тукталышына кадәр килергә кирәк (10, 10А, 22, 28, 28А, 30, 35, 54, 63, 89, 91 номерлы автобуслар, 2, 3, 5, 7, 8 номерлы троллейбуслар).

Керү – шәхесне таныклаучы документ күрсәтеп.

1.3.2. Дәүләт комитетының технологик аудит бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: (843) 221-82-28, (843) 221-82-61.

Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://kt.tatarstan.ru. Дәүләт комитетының электрон почтасы адресы: kt@tatar.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Дәүләт комитетының урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат Мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысуллар белән алынырга мөмкин:

1) Дәүләт комитетына телдән (шәхсән яки белешмә телефоны буенча) мөрәҗәгать иткәндә;

2) Дәүләт комитетына язма рәвештә, шул исәптән почта аша яисә «Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе» аша электрон рәвештә (E-mail: kt@tatar.ru);

3) дәүләт хезмәте турында Дәүләт комитеты биналарында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша – мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү урыннарында.

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

Стендларда әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) күрсәтелгән мәгълүматлар булырга тиеш.

4) «Интернет» челтәре аша:

Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/).

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Дәүләт комитетының рәсми сайтында һәм Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында бүлек белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.3.5. Дәүләт комитеты урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Дәүләт комитетының электрон почта адресы турында мәгълүмат Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4159 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык энергиясе чыганакларында (электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш), шул исәптән җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу максатларында, җылылык энергиясен, җылылык энергиясен саклаучы матдәне тапшырганда технологик югалтулар нормативларын, җылылык энергиясен җитештергәндә чагыштырма ягулык чыгымы нормативларын билгеләү тәртибе турында» 2012 елның 10 августындагы 377 номерлы боерыгы белән расланган Җылылык энергиясе чыганакларында (электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш), шул исәптән җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу максатларында, җылылык энергиясен, җылылык энергиясен саклаучы матдәне тапшырганда технологик югалтулар нормативларын, җылылык энергиясен җитештергәндә чагыштырма ягулык чыгымы нормативларын билгеләү тәртибе (Российская газета, 2014, 14 май, №292, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык электростанцияләрендә ягулык запасларын булдыру һәм файдалану тәртибен, шул исәптән ягу сезонында, раслау турында» 2013 елның 22 августындагы 469 номерлы боерыгы (алга таба – Тәртип) (Российская газета, 2014, 14 май, № 106);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары (алга таба – 468 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 04.08.2010, № 29, 1195 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы», 2010, № 46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Дәүләт комитеты җибәргән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгать. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 1 нче кушымтада китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау | № 190-ФЗ федераль законның 5 статьясы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты | 468 номерлы ТР МК карарының 4.2.19 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында боерык яки нормативларны раслаудан баш тарту турында хәбәр | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт | Гариза кергәннән соң 60 календарь көне эчендә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган боерык күчермәсен аңа теркәлә торган хат белән җибәрү аңа имза салган һәм аны теркәгән көннән башлап ике календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслаудан баш тарту турында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган хәбәрне мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул (почта, электрон почта адресы буенча) белән җибәрү баш тарту турында хәбәргә кул куелган көннән башлап ике календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Гариза (1 нче кушымта).<br>2. Раслау өчен тапшырылган нормативларның мәгънәсен нигезләүче документлар, ә атап әйткәндә:<br>- Тәртипкә туры китереп әзерләнгән, котельныйларда ягулык запасы булдыру нормативларын исәпләү нәтиҗәләренең җыелма таблицасы;<br>- аңлатма язуы;<br>- һәр ягулык төре буенча котельныйларда ягулаыкның гомуми технологик запасларын булдыру нормативы исәпләмәсе;<br>- котельныйларның ышанычлы һәм тотрыклы эше һәм җылылык энергиясен планлы эшләп чыгаруны тәэмин итү өчен кирәкле ягулыкның һәр төре буенча аерым котельныйларда төп һәм резерв ягулык төрләренең эксплуатация запасын булдыру нормативы исәпләмәсе;<br>- елның иң салкын аендагы шартлар буенча минималь исәпләнгән җылылык басымы һәм төп корпуста, ярдәмче биналарда һәм корылмаларда плюс температурасын саклап тору мөмкинлеген бирүче җиһазлар составы белән «исән калу» режимында котельныйлар эшен тәэмин итү өчен кирәкле ягулыкның һәр төре буенча аерым котельныйларда | Тәртипнең 2, 12, 16, 19, 21, 26 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | ягулыкның кимеми торган запасын булдыру нормативы исәпләмәсе;<br>- иң салкын ай өчен җибәрелгән җылылык энергиясенә чагыштырма ягулык сарыфын исәпләү;<br>- котельныйларда ягулык запаслары булдыру нормативлары күрсәткечләрен нигезләүче материалларның экспертизасы буенча бәяләмә.<br>Аңлатма язуында түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>- җылылык энергиясе чыганакларына сыйфатламалар;<br>- алыну чыганакларын күрсәтеп, энергия җитештерүнең фаразланган күләмнәре;<br>- тышкы факторларның әһәмиятләре: яндырыла торган ягулыкның структурасы һәм сыйфаты, ягулыкны китерү һәм саклау ысулы, тәэминатчылар, каты ягулыкны һәм сыек ягулыкны саклау өчен мазут савытларын саклау өчен склад бүлмәләренең булуы, алдагы өч ел өчен айлар буенча ягулык чыгымнары, алдагы өч елда һәр айның 1 нче көненә булган ягулыкның фактик запаслары;<br>- «исән калу» режимында эшләүче җиһаз составын нигезләү;<br>- тәэмин итүдән өзелми торган кулланучылар исемлеге һәм күрсәткечләре.<br>Таныклау шарты белән, документларның төп нөсхәләре урынына аларның күчермәләрен тапшыру рөхсәт ителә.<br>Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу - рөхсәт ителми.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.<br>Гариза белән документлар шулай ук Мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документарны һәм мәгълүматларны тапшыру таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Әлеге Регламентның 1.2 пункты нигезендә Мөрәҗәгать итүче булып тормаган затның документлар белән мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтен алучының (мөрәҗәгать итүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүнең, шулай ук дәүләт хезмәте алучы (мөрәҗәгать итүче) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Югарыда күрсәтелгән көтү вакытына төшке аш вакыты һәм эш вакыты булмаган вакыт кертелми<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү чоры һәм тәртибе | Гариза кергәннән соң бер календарь көне эчендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә:<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | системасы белән;<br>мәгълүмати стенд белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә<br>Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә аша, интернет аша дистанцион режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат мәгълүмат такталарында Дәүләт комитетына төп керү юлы янында һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү урынында, мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә прецедентлар | 880 номерлы ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүченең ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^{1}$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | (нигезләнгән шикаятьләр) булмау;<br>4) гариза бирүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы – 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>Дәүләт комитеты бинасының җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында Дәүләт комитеты мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны Интернет челтәрендә Дәүләт комитетының мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша гариза тапшыру һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу мөмкинлеге (мондый мөмкинлек тудырылганнан соң).<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба - КФҮ) аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада тапшыру мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы).<br>Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) аша электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеген тормышка ашырганнан соң, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәр административ процедураның (гамәлнең) тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, Мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү;

3) мөрәҗәгать итүче тапшырган материалларны эшкәртү һәм анализлау барышында документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү;

4) исәпләмәләрне һәм тапшырылган материалларны анаизлау, ягулык запаслары нормативларын раслау турында яки нормативларны раслаудан баш тарту турында карар кабул итү;

5) Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен юллау;

6) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм Мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яисә) «Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы» аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яки) хат аша мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы заты аша яки почта, Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында гаризаны Дәүләт комитетының гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлегенә тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.

3.3.2. Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында (алга таба – электрон документ әйләнеше) теркәү номерын беркетеп һәм кабул итү датасын күрсәтеп терки;

документларны кабул итү датасы, беркетелгән кереш номеры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында тамгалап, гариза күчермәсен почта буенча яки электрон почта (ихтыярына карап) аша мөрәҗәгать итүчегә тапшыру яки җибәрү;

гаризаны электрон документ әйләнеше аша электрон формада Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) (алга таба – рәис (рәис урынбасары) җибәрү.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм рәискә (рәис урынбасарына) җибәрелгән гариза.

3.3.3. Рәис (рәис урынбасары) гаризаны карый һәм рәис урынбасарына карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен рәис урынбасарына җибәрелгән гариза.

3.3.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм Бүлек башлыгына карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза.

3.3.5. Бүлек башлыгы гаризаны һәм документларны карый, җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм карау өчен аңа җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер календарь көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган гариза һәм документлар.

3.4. Документларны эшкәртү барышында документларны тикшерү

Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында эш формалаштыру (барлык документларны аерым папкага туплау);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән исемлеккә туры килү-килмәве буенча документларны тикшерә һәм түбәндәге документларны формалаштыра: тупланыш, күрсәтелгән кушымталарының булуы, таныклаучы реквизитларның (имза, штамп, теркәлү номеры, алучының фамилиясе һәм телефон номеры) булуы.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач ике календарь көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тикшерелгән документлар.

3.5. Кисәтүләрне бетерү кирәклеге турында гариза бирүчегә хәбәр әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларның тулы булмаган комплект белән җибәрелгән очракта яки алар Тәртип таләпләренә туры килмәгәндә, шулай ук техник хаталары булган яки рәсмиләштерелүе билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документлар җибәрелгәндә Бүлек белгече кисәтүләрне бетерү һәм җитешмәгән һәм (яки) кисәтүләрен исәпкә алып эшләп бетерелгән документларны Дәүләт комитетына җибәрү зарурлыгы турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәрне (алга таба – хәбәр) килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагысы тәмамланган көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында хәбәр.

3.5.2. Бүлек җитәкчесе хәбәрне карый, килештерә һәм аны рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагысы тәмамланган көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында килештерелгән хәбәр.

3.5.3. Рәис урынбасары, хәбәрне карап, аңа кул кую турында карар кабул итә һәм аны гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер календарь көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында имзаланган хәбәр.

3.5.4. Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече хәбәрне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагысы тәмамланган көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хәбәр.

3.5.5. Хәбәр җибәрелгән вакыттан башлап утыз календарь көне эчендә документлар тупланышының составы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бетерелмәсә, Бүлек белгече Бүлек башлыгы белән алдан килештереп, Рәис урынбасарының имзасы белән җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәр әзерли һәм аны гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кисәтүләрне бетерү срогы беткән вакыттан башлап бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җылылык энергиясе чыганакларына ягулык запаслары нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәр.

3.5.6. Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәрне терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәис урынбасары хәбәргә кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән

хәбәрләмә.

3.6. Җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында боерык әзерләү.

3.6.1. Документлар комплектына искәрмәләр булмаган очракта яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан кисәтүләрне бетергәннән соң, Бүлек белгече тапшырылган материалларны һәм исәпләмәләрне Тәртиптә белдерелә торган таләпләргә туры килү-килмәве буенча анализлый һәм җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында боерык проектын әзерли һәм аны килештерү өчен Бүлек башлыгына, юридик бүлек башлыгына, гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге башлыгына һәм рәис урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач илле календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җылылык энергиясе чыганакларына ягулык запаслары нормативларын раслау турында боерык проекты.

3.6.2. Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге җитәкчесе һәм рәис урынбасары боерык проектын карый, килештерә һәм имзалау өчен рәискә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач өч календарь көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге башлыгы һәм тикшерүдә тотучы рәис урынбасары белән килештерелгән, рәискә кул кую өчен юнәлдерелгән җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында боерык проекты.

3.6.3. Рәис җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында боерыкны карый, имзалый һәм гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер календарь көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган боерык.

3.6.4. Бүлек белгече боерык күчермәсен имза кую өчен Рәис урынбасарына җибәрү өчен, бүлек башлыгы белән алдан килештереп, теркәп җибәрелә торган хатны әзерли.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер календарь көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: боерык күчермәсе белән теркәп җибәрелә торган хат проекты яки җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәр.

3.6.5. Рәис урынбасары Бүлек башлыгы белән алдан килештереп, озату хатына кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер календарь көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: боерык күчермәсе белән теркәп җибәрелә торган хат яки җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын

раслаудан баш тарту турында хәбәр.

3.6.6. Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече:

теркәп җибәрелә торган хатны яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәрләмәне терки;

җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында карардан өземтә белән бергә теркәп җибәрелә торган хатны яки җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәрне мөрәҗәгать итүчегә почта буенча җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар озату хаты имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау турында боерык күчермәсен теркәп җибәрелгән хат яки җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслаудан баш тарту турында хәбәр.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза Мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, шул исәптән электрон почта ярдәмендә, яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы» аша җибәрелә.

3.7.1. Документларны кабул итү өчен җаваплы гомуми тәэмин итү һәм эш башкару белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәп тапшырылган документлары белән бергә терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер календарь көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.7.2. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында шушы Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны башкара һәм яңадан үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны Мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның чын нөсхәсен алып калып тапшыра яки Мөрәҗәгать итүче адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында

гариза алынганнан соң өч календарь көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (почта яисә электрон адрес буенча җибәрелгән) җавап.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган заты һәм рәис урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләрнең Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Дәүләт комитеты актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт комитетының еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә гаепле затларны җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләрне (гамәл кылмауны) һәм карарларны югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять кылу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының йә Дәүләт комитеты дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитетына шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә рәис карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки)

дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Дәүләт комитетының рәсми сайтыннан (http://kt.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6. 5.5 пунктның 1һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта әлеге пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә

ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Оешманың фирма бланкында
(оешма реквизитлары)

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитеты рәисенә
___________________________
(инициаллары

# ГАРИЗА

Җылылык энергиясе чыганагында ягулык запаслары нормативын раславыгызны үтенәм
_________________________________________________________________________
(оешманың аталышы)

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы
_________________________________________________________________________
(торак пункт, муниципаль район аталышы)

тарифларны дәүләти җайга салу чорына ________________ ел.
(җайга салу чорын күрсәтергә)

Кушымта: ________________________________________________________________

(теркәлүче документларны кыскача тасвирлау)

___________________________________ ______________ ________________________

(җитәкченең вазыйфасы) (имза) (Ф.И.А.)

мөһер урыны

Электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә
___________________________
(инициаллары, фамилиясе)

Техник хата төзәтү турында гариза

Җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының ________________ № _______ боерыгында җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:____________________________________________________

Дөрес белешмәләр:_____________________________________________________

Техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган боерыкка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1______________________________________________________________________;
2______________________________________________________________________;
3______________________________________________________________________.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны:

түбәндәге адреска электрон документ җибәрү юлы белән: ___________;

түбәндәге адрес буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша ________________________________________ адресы буенча җибәрүне сорыйм.

Электр энергиясе җитештерүнең билгеләнгән куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган электр һәм җылылык энергиясен катнаш режимда эшләп чыгару режимында функцияләүче җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның башкарылуын тикшерүдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме, Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе | 221-82-18 | кt@tatar.ru |
| Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары | 221-82-04 | Liliya.Borisova@tatar.ru |
| Технологик аудит бүлеге башлыгы | 221-82-28 | Yuliya.Shayhutdinova@tatar.ru |
| Гомуми тәэмин итү һәм эш башкару бүлеге белгече | 221-82-94 | кt@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге башлыгы | 264-76-02 | Fail.Salihov@tatar.ru |